

Мордовия махсус хәрби операциядә катнашучыларга кирәк булган әйбер-ләрне жыю һәм тапшыру дәвам итә. Игелекле эштә менләгән кеше, жәмгыть эшлеклеләре, предприятие һәм оешмалар катнаша.

Олкән буын «Бердәм Россия» партия проекты кысаларында оештырылган «Герой очен жылылык» хәйрия акциясе Торбеево район халкы арасында да зур ярдәм тапты. Гуманитар ярдәм кабул итv пунктында махсус хәрби операциядә катнашучылар очен берничә йоз пар жылы носки һәм хат тупланган. Чираттагы тапкыр «Герой очен жылылык» акциясе Ватанны саклаучыларна ярдәм кvрсәтте. Хатын-кызларнын һәр сvзенә һәм һәр эшләнмәсенә кvнел жылысынын, Ана мәхәббәтенен һәм ойнен бер олешен салганнар.      Акциядә торле яшьтәге битараф булмаган гражданнар, шул исәптән эшләvчеләр һәм яшьләр дә катнашты. Директор, партия әгъзасы Журавлева Галина Васильевна житәкчелегендә йоздән артык пар жылы оекбаш әзерләгән «Очаг» автоном коммерциячел булмаган оешма хезмәткәрләре аерым рәхмәт сvзләренә лаек булды. Галина Васильевна: «Осталарыбыз Наилә Хамиль кызы Агишевага, Лидия Филипповна Маслихинага, Мария Алексеевна Тимошкинага, Людмила Михайловна Кабановага, Ирина Александровна Кидяевага, Любовь Васильевна Жилкинага, Татьяна Васильевна Журавлевага, Надежда Владимировна Жилкинага, Татьяна Ивановна Китаевага, Светлана Анатольевна Моисеевага зур рәхмәт әйтәсем килә...»

Ватанны саклаучылар коне алдыннан якташларыбызга, махсус хәрби операциядә катнашучыларга, жылы бvләкләр һәм рәхмәт сvзләре язылган хатлар тапшырылачак, һәм, һичшиксез, аларга туган яктан котеп алынган хәбәрләре булачак.

**Асия АГИШЕВА**